лып, Аллаһы хозурына кайтарылачаклар».

*«Хайваннарда да сезнең өчен файдалы гыйбрәтләр бар. Аларның эчендә яралтылганнарны (сөтне) сезгә эчертәбез. Алардан сез бик күп файдалар күрәсез. Итләрен дә ашыйсыз».*

*«Бер-берсенә уралып үскән җимеш бакчаларын сугара».*

*«Ул агачта һәм куаксыз өлгерә торган җимеш бакчаларын, җиләк-җимешләрне вә татлары төрле-төрле хөрмәләрне, игенашлыкларны, зәйтүннәрне, нар җимешләрен бер-беренә охшаш та, бер-беренә охшамаган итеп тә яралтты. Уңыш-җимеш биргән вакытта һәрберсеннән авыз итегез. Урыпҗыйган көнне хакын (садакасын, зәкятен) бирегез. Исраф итмәгез. Аллаһы исрафчыларны сөйми. (Аллаһы ризыкны максатсыз әрәм-шәрәм итүгә катгый каршы)».*

Коръән билгеләгән иман, гыйбадәт һәм әхлак нигезләре белән кешене өйрәтүне максат итә.

Коръәннең иң төп темасы - кеше, инсан. Кешене матур, гүзәл әхлаклы кылу. Аның өчен кешегә иң элек иман нигезләрен өйрәтә. Ахирәт көнендә Аллаһының кешеләрдән дөньяда ясаганнарының хисабын сораячагын белдерә. Бу рәвешле иман итүче кешеләрнең яхшылыкны хәрәкәт рәвешенә әйләндерүен, начарлыклардан читләшүен тели. Шушы сәбәптән Коръән үзен болай дип таныта:

*“Сезне караңгылыктан яктылыкка алып чыгар өчен, колына ап-ачык аятьләр иңдергән Аллаһы булыр. Шик юктыр ки, Аллаһы сезгә бик тә мәрхәмәтле һәм шәфкатьле”.*

Кешеләргә яхшылыкны боерып, начарлыклардан тайпылуны теләүче Коръән болай дип боера: *“Мөэмин ирләр белән мөэминә хатыннар бер-берләренең дустыдыр. Алар игелек юлына өнди, яманлыклардан баш тартырга үгетлиләр, намазларын калдырмыйлар, зәкят бирәләр, Аллаһыга һәм Аның Рәсуленә итагать итәләр. Менә шундыйларга Аллаһы рәхмәтен бирер. Шик юк ки, Аллаһы - бөек һәм хикмәт ияседер”.*

**Рәҗәп КЫЛЫЧ.**

*(“Иман” газетасыннан)*

# Ризыгыңны арттырыр өчен

Ярлылык һәм бөлгенлек мәсьәләсе ислам динендә мөселманның үз тормышын яхшыртырга тиешле дигән фикер белән генә каралмый.

Чынлыкта, фәкыйрьлек иман өчен дә куркыныч икән.

Мөселманнарны һәм ислам җәмгыятен фәкыйрьлек, артта калучанлык белән бәйләргә тырышучы икейөзле кешеләр бар, ләкин бу – ялган һәм көнбатышлыларның аларча булмаган гореф-гадәтләр белән көрәшүе генә.

Аз гына булса да ислам дине белән таныш кешегә диннең яхшы, җитешле тормышка, җәмгыятьнең чәчәк атуына өндәве мәгълүм.

Ислам цивилизациясенең үсеше һәм чәчәк атуы моңа ачык мисал булып тора.

Ә хәзерге мөселман илләренең бөлгенлегә һәм неоколониализмга дучар булуы мөселманнарның диннән тайпылышыннан гыйбарәт, чөнки ислам диненең моңа катнашы юк.

Аллаһы Илчесе дә: *«Йә Раббым, Сиңа көферлектән, бөлгенлектән, кабер газабыннан сыенам, Синнән башка илаһлар юк»*, - дип дога кылган.

Ислам дине, әлбәттә, сукырларча, бертуктаусыз байлык туплауны хупламый, ләкин ул җитешле һәм бай тормышка каршы килми. Әгәр фәкыйрьлекне хуплаучы дини вәгазьләрне очратсагыз, белегез: алар фәкыйрьлекне түгел, ә иманны ныгытуны хуплый.

Кайвакытта кеше күпмедер байлык алырга теләп тырыша, ләкин мөмкинчелек булмый. Кайвакытта Аллаһы Тәгалә аны бөлгенлек белән сыный, шунда инде бәндәнең иман ныклыгы ачыклана. Аллаһы шундый кешеләргә әйтә: *«Кайгырмагыз, сез югарырак дәрәҗәдә, әгәр иман китерсәгез»* («Әәл Гыймран» сүрәсе, 139 нчы аять).

Бөлгенлеккә төшкән кешедә Аллаһының гадел булуында шик уянырга мөмкин (андый мисаллар бар). Бу бәндә Аллаһы тыйган гамәлләрне эшли башлый, әйтик, урлаша, зина юлы белән акча эшли. Бүген мөселман кешесенең ярлы булуы аеруча куркыныч, чөнки хәзерге вакытта байлыкка мәхәббәт «тәрбияләнә».

Безнең гасырда дин дошманнары исламны артта калган дин итеп күрсәтергә телиләр. Хәзер гадел юл белән баеп булмый дигән фикер йөри. Баер өчен бар нәрсәне дә сатарга кирәк: намусны да, иманны да. 15нче гасыр узгач, кайбер мөселманнар Аллаһы дошманнарының өч тиенлек ярдәмнәре белән ләззәтләнәләр (төрле секталарга сатылу үзе генә дә ни тора!). Аллаһы Илчесе дә бит: *«Мөселманның ярлылыгы аны кяферлеккә төшерү чарасы булу белән бик куркыныч»*. Шуны онытмыйк: ислам гадел рәвештә акча эшләү юлларын күрсәтә, ә Аллаһы ризыкландыра.

Динебез байлыкны арттыру буенча берничә юл күрсәтә:

1. Әүвәл тәүбә итәргә кирәк. Тәүбә – гөнаһларны кылмый башлау дигән сүз. Пәйгамбәр саллаллаһу гапәйһи вәсәлләм әйтә: *«Кем еш тәүбә итә, Аллаһы шуңа авырлыклардан котылу юлын күрсәтә, кайгысын җиңеләйтә, көтелмәгән җирдән ризыкландыра».*

2. Аллаһыдан курку да шулай ук ризыкны киңәйтә. Тәкъвалык (Аллаһыдан курку) Аллаһы кушканны үтәү, тыйганнан тыелуны күрсәтә. Коръәндә: *«Кем Аллаһыдан курка, шуңа тормыш итәр өчен көтмәгән җирдән байлык бирә»*, – диелә. Аллаһы Илчесе әйтә: *«Гөнаһ аркасында бәндәнең ризыгы кими»*.

3. Аллаһыга дөрес итеп тәвәккәлләү. Мөселман Аллаһының: *«Сез Аллаһыга мох-*



*таҗ, ә Ул бернәрсәгә дә мохтаҗ түгел»*, – дигән сүзләренә ышанса, ул Аллаһы каршында үзенең зәгыйфьлеген тоя, Аңа гына таянырга кирәклеген аңлый. Аллаһы әйтә: *«Кем Аллаһыга тәвәккәлли, Ул аның өчен җитә»* («әт-Талак» сүрәсе, 3нче аять).

4. Кушканнарны үтәү юлы белән, йөрәкне байлык мәсьәләләреннән коткару. Аллаһы кодси хәдистә әйтә: *«Әй Адәм баласы, миңа тулысынча табыныгыз. Мин сезне бөлгенлектән коткарам».*

5. Мохтаҗ кешеләргә, шәкертләргә садакалар бирү.

6. Инвалидлар, мохтаҗларга булышу.

**Габдрахман ХӘБИБУЛЛИН.**

*(«Ислам-инфо»)*

# Ипигә хөрмәт турында

Ипи – кеше өчен һәрвакытта да, хәтта Адәм (г.с.) заманыннан башлап иң мөһим ашамлык. Коръәндә “Йәсин” сүрәсендә ипи турында болай диелә: “Җирдән кешеләр һәм хайваннар ашый торган күптөрле ризыклар чыгардык, шуларны уйлап карамыйлармы?”

Пәйгамбәребез (с.г.в.с.) әйтә: *«Ипине хөрмәт итегез. Чөнки ипине Аллаһы хөрмәт итә. Кем ипине хөрмәт итсә, Аллаһы аны хөрмәт итәр».*

Аллаһы Тәгалә аяти-Кәримәдә әйтә: *«Без кешене дөньяда яшәтер өчен кайбер әйберләрне үтерәбез, терелтәбез»*. Галимнәр баш вата: ни өчен Аллаһы Тәгалә шулай дип әйтә? Нигә башта терелтәбез, аннары үтерәбез, ди. Тикшерә башлагач, моның мәгънәсенә төшенделәр. Дөньяда бер әйбер яшәсен өчен икенчесе үләргә тиеш. Шуңа күрә галимнәребез ипи турында әйтә: «Кеше яшәсен өчен иң күп үлә, газап күрә торган ризык – ул икмәк». Әл-Мәүләнә хәзрәтләре бик матур итеп мисал китерә: «Иң башта иген чәчәбез. Ул яшел булып калка, үсеп туктагач саргая. Бу чакны, икмәк өлгерде, дип әйтәбез. Аның икенче мәгънәсе – үлде дию. Без аңа күпме генә су сипсәк тә, ул башка яшелләнмәячәк. Беренче мәртәбә үлә. Аннары без аны урабыз. Икенче тапкыр үлә. Сугабыз, җилгәрәбез, тегермәндә тарттырабыз. Өченче тапкыр үлә. Оннан камыр ясыйбыз, пешерергә мичкә тыгабыз. Тагын үлә. Мичтән соң кисәкләргә бүләбез. Бу да үтерү. Аннан соң тешләр белән чәйнәү. Соңгы үтерү – аны ашказаныбыз эшкәртә».

Кеше яшәсен өчен ипи никадәр җәфа күрә. Шуңа күрә кеше ипине хөрмәт итәргә тиеш. Ипине ашаганда, кеше артыгын алмасын, исрафка юл куймасын. Җәмәгать урынында ашаганда ипи кыерчыгы калса, аны салфеткага төреп өйгә алып кайту мәслихәт. Чүплеккә бер грамм ипи дә китмәсен. Ипи валчыкларын өстәлдән җыеп ашау, хәтта идәннән алу саваплы эш. Ә ипи өстенә әйбер кую аны хөрмәтсезләү була. Өстәлдә ипидән югарырак һичбер ризык тормаска тиеш. Элеккеге заманнарда өстәлләрдә бар ризыклар бер тигезлектә иде. Хәзерге вакытта биек-биек савытлар барлыкка килде. Алар исә бер ризыкны икенчеләреннән өскәрәк күтәрә. Бу икенче ризыкның дәрәҗәсен төшерү була. Пәйгамбәребез (с.г.в.с.) өч көн рәттән ипи ашамаган. Аңа шулай хөрмәт күрсәткән.

Элекке заманнарда ак ипи байларның өстәлендә генә булган. Хәзрәте Гомәр хәлифә булганда тикшерү эшләре белән Йәмәнгә килгән. Шәһәрдә аны иң олы байлар каршы алганнар, мәҗлесләр әзерләгәннәр. Берчакны табынга утыргач, хәзрәте Гомәр өстәлдә ак ипи күргән. Ул вакытта ак ипи байларда гына булган. Хәзрәте Гомәр сораган: «Ак ипине шәһәрдәге бөтен кеше дә ашыймы?» «Юк, аны иң кадерле кунакларга гына бирәбез», – диләр. Гомәр әйтә: «Ул вакытта мин дә аны ашамыйм. Бөтен мөселманнар белән тигез булырга тиешмен», – ди.

Пәйгамбәребез (с.г.в.с.) әйтә: *«Ипи җирнең һәм күкнең бәрәкәте»*. Ипине ташласак, без үзебезгә тиеш булган бәрәкәтне кулдан ычкындырган булабыз. Иманлы кеше ипине беркайчан да чүпкә ташламас.

Хәзерге заман өчен ипи бик мөһим булып күренмәсә дә, мәгънәви яктан карасак, аның мөһимлеген аңлыйбыз. Әмма бернинди ризыкны да ипидән югарырак күтәрергә ярамый, дигәнне дөрес аңлау кирәк. Бу ипигә табыну кебек кабул ителмәскә, ширеккә юл ачмаска тиеш. Шуңа күрә ипи белән ант итү дә дөрес түгел.

**Сөләйман хәзрәт ФӘХРИЕВ,**
**Чаллының “Нур-Ихлас” мәчете имамы.**

*(“Татар мөселман календаре”ннан)*

# Дога кылуга таләпләр

Билгеле булганча, исламда дога кылу – бик тә җитди һәм катлаулы гамәл. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәлам әйткәнчә, «дога – гыйбадәтнең асылыдыр». Дога кылу гыйбадәте дини тормышыбызда мөһим бер урын алып тора.

1. Дога кылганда өскә таба кулларны туры күтәрергә, ләкин күзләрне югары текәмәскә кирәк. Мөслим риваять иткән бер хәдистә Пәйгамбәребез галәйһис-сәлам хәзрәтләре болай дигән: *«Бер төркем кешеләр намаз, дога кылганда күзләрен күккә текәүдән ваз кичсеннәр, әгәр ваз кичмәсәләр, күзләре сукыраер»*. 2. Доганы тәһарәт алып, ике рәкәгать яки аннан да күбрәк намаз кылганнан соң гына укырга тырышыгыз.

3. Тәүбә, истигъфар һәм дога кылучы кеше дога кылачак кичәнең көндезен, мөмкинлекләреннән чыгып, фәкыйрьләрне, ятимнәрне садака биреп сөендерергә, күңелен күрергә тиеш. Ире төрмәдә яки хәрби хезмәттә булган хатын-кызларның кайгыларын уртаклашырга, аларга ярдәм итәргә кирәк. Дога кылудан элек берничә көн ураза тоту да саваплы.

4. Дога кылганда кыйбла тарафына карарга кирәк. Чөнки дога гыйбадәттер һәм гыйбадәт вакытында бәндә кыйблага юнәлергә тиеш.

№ 44 (1171), 27 октябрь 2012 ел

Бердәмлек